КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 май г.Казань № 361

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1245 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 19 февраль, 141 нче; 2022 ел, 15 июнь, 566 нчы; 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләрендә һәм мәдәният-ял итү учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләрендә һәм мәдәният-ял итү учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының башкару сәнгате буенча дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография

хезмәткәрләре вазифалары һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләре һәм эшләнмәләре өлкәләре хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин